**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№448**
**02.02.2022**

Җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участогыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт һәм муниципаль милектәге җирләрдә һәм җир участокларында җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4404 номерлы карары белән расланган җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участогыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын озайту гариза бирүчегә тиешле белдерү кәгазен җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта муниципаль хезмәтне башкаруны озайту срогы биш эш көненнән дә артмый.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 2.17 пункт өстәргә:

«2.17. Рөхсәт бирелә торган срок.

2.17.1. Рөхсәт гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән, әмма биш елдан артмаган срокка бирелә.»;

3) 3.4.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазьләре (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда, ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы

вазыйфаи затка җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов